**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 22 февраль № 114

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 25 май, 353 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 ел, 25 май, 353 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген

формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибенә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\114.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 25 май, 353 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 22 февраль, 114 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе

1. Әлеге Тәртип, дәүләт мөлкәтен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга озак вакытлы нигездә хуҗа булуга һәм (яки) файдалануга бирү максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлештә күздә тотылган Татарстан Республикасы милкендә булган (җир кишәрлекләреннән тыш), өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) мөлкәт исемлеген (алга таба тиешенчә – дәүләт мөлкәте, исемлек) формалаштыру, алып бару (шул исәптән ел саен өстәмәләр кертү) һәм мәҗбүри бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Исемлеккә түбәндәге критерийларга туры килгән дәүләт мөлкәте турында мәгълүматлар кертелә:

а) дәүләт мөлкәте өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш);

б) дәүләт мөлкәте әйләнештә чикләнмәгән;

в) дәүләт мөлкәте дини әһәмияттәге объект булып тормый;

г) дәүләт мөлкәте төзелеше төгәлләнмәгән объект булып тормый;

д) дәүләт мөлкәтенә мөнәсәбәтле аны башка затларга бирү турында Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителмәгән;

е) дәүләт мөлкәте Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) кертелмәгән;

ж) дәүләт мөлкәте авария хәлендә һәм сүтелергә яки төзекләндерелергә дип танылмаган.

3. Исемлеккә дәүләт мөлкәте турында мәгълүматлар кертү (шул исәптән ел саен өстәмәләр кертү), шулай ук исемлектән дәүләт мөлкәте турында мәгълүматларны алу Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен белдерә торган гомумроссия коммерциягә карамаган оешмалар, кече һәм урта эшмәкәрлек субъ-

ектлары инфраструктурасын төзи торган оешмалар, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тәкъдимнәре нигезендә исемлекне раслау турында яки аңа үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) карары белән гамәлгә ашырыла.

Исемлеккә дәүләт мөлкәтен исемлектән алуны күздә тотмаган үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән тәкъдимне карап тикшерү ул кертелгән көннән соң 30 календарь көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тәкъдимне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, аңа мөнәсәбәтле тәкъдим кертелгән дәүләт мөлкәте турында мәгълүматларны исемлеккә кертү хакында;

б) әлеге Тәртипнең 6 нчы һәм 7 нче пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, аңа мөнәсәбәтле тәкъдим кертелгән дәүләт мөлкәте турында мәгълүматларны исемлектән алу хакында;

в) тәкъдимне исәпкә алудан баш тарту турында.

5. Әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән тәкъдимне исәпкә алудан баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган тәкъдимне керткән затка дәүләт мөлкәте хакындагы мәгълүматларны исемлеккә кертү яки дәүләт мөлкәте турындагы мәгълүматларны исемлектән алу мөмкин булмавы хакында мотивлаштырылган җавап җибәрә.

6. Дәүләт мөлкәте турында мәгълүматларны исемлеккә керткән көннән соң ике ел дәвамында әлеге мөлкәткә мөнәсәбәтле кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан яки кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары инфраструктурасын төзи торган оешмалардан түбәндәгеләр кертелмәсә, вәкаләтле орган дәүләт мөлкәте турында мәгълүматларны исемлектән алырга хокуклы:

а) дәүләт мөлкәтенә мөнәсәбәтле хуҗа булу һәм (яки) файдалану хокуклары күчүне күздә тоткан шартнамә төзү хокукына аукционда (конкурста) катнашуга бер заявка да кертелмәсә;

б) аңа мөнәсәбәтле әлеге шартнамәне төзү «Конкурентлылыкны яклау турында» 2006 ел, 26 июль, ФЗ-135 нче Федераль законда күздә тотылган очракларда аукцион (конкурс) үткәрмичә гамәлгә ашырылырга мөмкин булган дәүләт мөлкәтен бирү турында бер гариза да кертелмәсә.

7. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларның берсендә дәүләт мөлкәте турында мәгълүматларны исемлектән ала:

а) дәүләт мөлкәтенә мөнәсәбәтле законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт ихтыяҗлары өчен яисә башка максатларда аннан файдалану турында Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгән булса;

б) дәүләт мөлкәтенә Татарстан Республикасының милек хокукы суд карары нигезендә яки законнарда билгеләнгән башка тәртиптә туктатылган булса.

8. Дәүләт мөлкәте турында мәгълүматлар исемлеккә «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 18 статьясындагы $4^4$ өлеш нигезендә билгеләнгән составта һәм форма буенча кертелә.

9. Дәүләт мөлкәте турында мәгълүматлар исемлектә мөлкәт төрләре (күчемсез мөлкәт (шул исәптән бердәм күчемсез комплекс), күчмә мөлкәт) буенча төркемләнә.

10. Исемлекне алып бару вәкаләтле орган тарафыннан электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

11. Исемлек һәм аңа кертелгән үзгәрешләр:

а) раслаган көннән соң 10 эш көне эчендә «Республика Татарстан» газетасында мәҗбүри бастырып чыгарылырга тиеш;

б) раслаган көннән соң өч эш көне эчендә вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (шул исәптән ачык мәгълүматлар рәвешендә) урнаштырылырга тиеш.